ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

11.09.2019 — с. Введенская Слобода — №115

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п., Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү буенча бердәм инициатива күрсәтергә:

"2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 400 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Введенка Бистәсе авыл җирлеге территориясендә вак таш җәелгән юлда вак таш җәю һәм төзекләндерү:

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Введенка Бистәсе авыл җирлеге
Башлыгы — Д.В. Морозов